Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге составына керүче Зур Мәшләк һәм Югары Мәшләк торак пунктларында гражданнар җыены

# КАРАРЫ

18 ноябрь 2024 ел № 2

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Зур Мәшләк авыл җирлеге составына керүче Зур Мәшләк һәм Югары Мәшләк торак пунктларында гражданнар җыены нигезендә **карар кабул ителде**:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлегенең Зур Мәшләк һәм Югары Мәшләк авыл торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, 1 нче группа инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, торак пунктта теркәлгән, әмма теркәү урыны буенча 5 елдан артык яшәмәүче гражданнардан гайре ) 600 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга.

2. Зур Мәшләк һәм Югары Мәшләк торак пунктлары территориясендә:

- урамнарны яктырту җайланмалары урнаштыру;
- су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аларны чистарту, халыкка су бирүне (җибәрүне) тәэмин итүче суэтем башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын, су белән тәэмин итү һәм субүлү системаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- рөхсәтсез барлыкка китерелгән чүплекләрне юк итү.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: *Шамив* М.М.Шәмсевәлиев

Зур Мәшләк авыл җирлеге
Башлыгы вазыйфаларын башкаручы М.М.Шәмсевәлиев